ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ЕЛАБУЖСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АЛАБУГА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

---

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** 08.12.2023 1978 **КАРАР**

Алабуга муниципаль районы Башкарма комитетының «Автомобиль җәмәгать транспортында даими муниципаль маршрутлар буенча пассажирлар йөртүне гамәлгә ашыру хезмәтләреннән бертигез файдалану мөмкинлеген тәэмин итү белән бәйле рәвештә аерым категориягә караган гражданнарга алынып бетмәгән керемнәрне каплау максатыннан Алабуга муниципаль районы бюджетыннан субсидияләр бирү турында» 2022 елның 8 декабрендәге 1630 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

Россия Федерациясе Бюджет кодексының 78 статьясы, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Юридик затларга, шәхси эшмәкәрләргә, шулай ук товарлар җитештерүче, эшләр башкаручы, хезмәтләр күрсәтүче физик затларга субсидияләр, шул исәптән субсидияләр рәвешендә грантлар бирүне җайга сала торган норматив хокукый актларга, муниципаль хокукый актларга карата гомуми таләпләр турында һәм Россия Федерациясе Хөкүмәтенең кайбер актлары гамәлдән чыгуын тану турында» 2020 елның 18 сентябрендәге 1492 номерлы карары, «Татарстан Республикасында муниципаль берәмлекләрнең җирле үзидарә органнарына Татарстан Республикасы территориясендә аерым категориядәге гражданнар өчен җәмәгать транспорты хезмәтләреннән бертигез дәрәҗәдә файдалану мөмкинлеген тәэмин итү өлкәсендә аерым дәүләт вәкаләтләрен бирү турында» 2008 елның 19 декабрендәге 123-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы законы нигезендә, Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. Алабуга муниципаль районы Башкарма комитетының «Автомобиль җәмәгать транспортында даими муниципаль маршрутлар буенча

пассажирлар йөртүне гамәлгә ашыру хезмәтләреннән бертигез файдалану мөмкинлеген тәэмин итү белән бәйле рәвештә аерым категориягә караган гражданнарга алынып бетмәгән керемнәрне каплау максатыннан Алабуга муниципаль районы бюджетыннан субсидияләр бирү турында» 2022 елның 8 декабрендәге 1630 номерлы карары белән расланган, автомобиль җәмәгать транспортында даими муниципаль маршрутлар буенча пассажирлар йөртүне гамәлгә ашыру хезмәтләреннән бертигез файдалану мөмкинлеген тәэмин итү белән бәйле рәвештә аерым категориягә караган гражданнарга алынып бетмәгән керемнәрне каплау максатыннан Алабуга муниципаль районы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 6.1 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:
«Сайлап алуда катнашучыларның тәкъдимнәре (гаризалары) Алабуга муниципаль районы Башкарма комитеты тарафыннан 12-28 декабрь көннәрендә һәр көнне 17:00 сәгатькә кадәр түбәндәге адрес буенча кабул ителә:
Алабуга шәһәре, Мир проспекты, 12 нче йорт, 123 нче кабинет, шулай ук электрон почта адресы аша: otdeltransporta@bk.ru».

1.2. 25 пунктның икенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:
«Субсидия күләме түбәндәге формула буенча исәпләнә: 2023 елга гражданнарга бердәм социаль юл билеты һәм бердәм айлык балалар социаль юл билеты буенча транспорт хезмәтләре күрсәтүгә бәйле рәвештә автотранспорт предприятиеләренә чыгымнарны компенсацияләү күләме».

1.3. Автомобиль җәмәгать транспортында даими муниципаль маршрутлар буенча пассажирлар йөртүне гамәлгә ашыру хезмәтләреннән бертигез файдалану мөмкинлеген тәэмин итү белән бәйле рәвештә аерым категориягә караган гражданнарга алынып бетмәгән керемнәрне каплау максатыннан Алабуга муниципаль районы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибенең 1 нче кушымтасындагы соңгы абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:
«Сайлап алуда катнашучыларның тәкъдимнәре (гаризалары) Алабуга муниципаль районы Башкарма комитеты тарафыннан түбәндәге адрес буенча кабул ителә:
Алабуга шәһәре, Мир проспекты, 12 нче йорт, 123 нче кабинет, шулай ук электрон почта адресы аша: otdeltransporta@bk.ru».

2. Әлеге карар рәсми рәвештә бастырып чыгарылырга тиеш.
3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

Җитәкче

ДОКУМЕНТ ПОДПИСАН ЭЛЕКТРОННОЙ ПОДПИСЬЮ
СВЕДЕНИЯ О СЕРТИФИКАТЕ ЭП
Сертификат: 30C33C67746B0C8EA9DE00B6707B1433
Владелец: Ахмадеева Эльмира Равильевна
Действителен с 19.10.2023 до 11.01.2025

Э.Р. Әхмәдиева

Лист согласования к документу № 1978 от 08.12.2023
Инициатор согласования: Мусина Е.А. Главный специалист организационного отдела
Согласование инициировано: 27.12.2023 14:36

**Лист согласования** Тип согласования: **последовательное**

| N° | ФИО | Срок согласования | Результат согласования | Замечания |
|---|---|---|---|---|
| 1 | Ахмадеева Э.Р. | | Подписано<br>27.12.2023 - 19:21 | - |